**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**25.10.2023** **1632**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 22 октябрендәге 2272 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Прокуратурасының 2023 елның 23 гыйнварындагы 02.08-01 номерлы протесты нигезендә, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 02 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 22 октябрендәге 2272 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.8.2 пунктчасының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ярдәм күрсәткән орган яки оешма тарафыннан билгеләнгән хокук бозуны бетерү срогы үтәлгән шартта, кече яки урта эшкуарлык субъекты тарафыннан мондый хокук бозуны алданрак бетерү очрагыннан тыш, кече яисә урта эшкуарлык субъектын ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозган дип тану датасыннан кимендә бер ел узган, ә ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозу ярдәм чараларын максатчан файдаланмау яисә дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру белән бәйле булган очракта, кече яисә урта эшкуарлыкны мондый хокук бозуны кылган дип таныган датадан өч елдан да азрак вакыт узган. Әлеге пунктта каралган нигезләмәләр, аларга карата ярдәм күрсәткән орган яки оешма тарафыннан кече яисә урта эшкуарлык субъекты тарафыннан ярдәм күрсәтү тәртибе һәм шартлары бозылуын ачыклаган ярдәм төрләренә кагыла.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин